Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Яңа Шашы авыл җирлеге Советы Карары

«30» октябрь 2020ел № 6

**11.11.2009 ел № 110 Яңа Шашы авыл җирлеге Советы карары белән расланган «Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү белән бәйле рәвештә Яңа Шашы авыл җирлеге Советы карар итте:

1 .Әтнә муниципаль районының «Яңа Шашы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» Яңа Шашы авыл җирлеге Советының 11.11.2019 ел, № 110 карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1.** 10 статьяның 2 пунктын үз көчен югалткан дип танырга

**1.2.** 34 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.Җирлек советы керемнәренең гомуми күләмен үзгәртүгә китерә торган һәм җирлек Советының бюджет турындагы карар проектын җирлек Советына керткәннән соң кабул ителгән карарларының нигезләмәләре Чираттагы финанс елында, агымдагы финанс елына һәм план чорына җирлек бюджетына үзгәрешләр керткәндә, агымдагы финанс елы күрсәткечләре өлешендә исәпкә алына.»

**1.3.** 27 статьяның 16 пунктындагы 5 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга

**1.4**. 15 статьяның 15 абзацын үз көчен югалткан дип танырга

**1.5**. 45 статьядагы 3 пунктта "түләү документлары" сүзләрен "казначылык түләүләрен башкару турында күрсәтмәләр (алга таба - күрсәтмә)" сүзләренә алмаштырырга, "түләү документлары" сүзләрен "күрсәтмә" сүзләренә алмаштырырга."

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында , Әтнә муниципаль районының Интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб –адресы буенча ) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында : (pravo.tatarstan.ru ) веб –адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Яңа Шашы авыл җирлеге башлыгы М.С.Сабирҗанов

Совет Новошашинского сельского поселения Яңа Шашы авыл җирлеге Советы